ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СУНЬСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Яруллина, д.7а, с. Малая Сунь,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422173

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТҮБӘН СОН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Яруллин ур., 7а нче йорт, Кече Сон авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422173

тел.(факс): (85563) 3-07-03; e-mail: Sun.Mam@tatar.ru, www:mamadнsh.tatarstan.ru

Постановление Карар

29 гыйнвар 2026 ел № 1

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Сон авыл җирлегендә җирлекара күмү урыннарында
җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен
раслау турында

«Күмү һәм күмү эше турында» 1996елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пункты һәм 12 статьясындагы 3 пункты (үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Сон авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 9678,63 сум күләмендә билгеләргә һәм 2026 нче елның 1 февраленнән 1 нче һәм 2 нче Кушымталар нигезендә гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге Башкарма комитетының 2025 елның 31 нчы январендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге җирле карары күмү урыннарында җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында » № 1 карарын гамәлдән чыкты дип танырга.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгагрырга һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсмисайтында (http://mamadysh.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.Ф.Мухаметзянов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Сон авыл җирлеге
Башкарма комитетының
29.01.2026 ел , № 1 карарына
1 нче кушымта

2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча Гарантияле исемлек нигезендә тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле үлгән (һәлак булган) очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәткүрсәтүатамасы | Хезмәткүрсәтүбәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен документлар әзерләү | 0 |
| 2. Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 4452,21 |
| 3. Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 1160,20 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4066,33 |
| Барлыгы | 9678,63 |

Татарстан  Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Сон авыл җирлеге
Башкарма комитетының
29. 01.2026 ел , № 1  карарына
2 нче кушымта

2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге
Җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә, тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәткүрсәтүатамасы | Хезмәткүрсәтүбәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. 1.Җирләү өчен документлар әзерләү | 0 |
| 2. Мәетне киендерү, кәфенләү | 1381,27 |
| 3.Гүргә индерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 3197,37 |
| 4.Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 1183,58 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәмкүмү) | 3916,42 |
| Барлыгы | 9678,63 |